Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк
авылы, Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» сентябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Башлыгының 2014 елның 22 февралендәге 5 номерлы «Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясендә кулланучылардан терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм эшкәртелгән терекөмеш лампаларны урнаштыру урыннары турында» карары үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 нчы номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда үтәлүе бәяләнә торган мәҗбүри таләпләргә ия федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын юкка чыгару турында» карарының 1 нче кушымтасы 34 нче пункты нигезендә, **карар чыгарам**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк Илбәк авыл җирлеге Башлыгының 2014 елның 22 февралендәге 5 номерлы «Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге территориясендә кулланучылардан терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм эшкәртелгән терекөмеш лампаларны урнаштыру урыннары турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы"нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәгет веб-адрес буеча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина